РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«31» март 2023 ел Олы Кайбыч ав. № 178

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарәсенең депутат, сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарәсе депутатына, сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен) сүзләренә алмаштырырга (алга таба - Татарстан Республикасы Рәисе)»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның 1,3 абзацларында «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин